**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**06.02.2019** **№ 237**

2019 елда балаларның һәм
яшьләрнең ялын һәм эш белән тәэмин итүен
оештыру турында

Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2019 елның мәктәп каникуллары чорында балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, аларны эш белән тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү дәүләт программасын» раслау турында 2014 ел, 7 нче февраль, 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 19 ноябрь, 1006 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2019 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 4 сентябрь, 748 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү дәүләт программасын” раслау турында 2014 ел, 7 нче февраль, 73 номерлы карарына нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымталарны расларга:

2019 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балалар һәм яшьләренең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итү программасын (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру турында нигезләмәне (2 нче кушымта).

Биектау муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне (3 нче кушымта).

Биектау муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствоара комиссия составы (4 нче кушымта);

2. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор Идарәсенең Биектау территориаль бүлегенә ташламалы шартларда уздыруны тәэмин итүне киңәш итәргә:

ял итү һәм сәламәтләндерү учреждениеләренең гамәлдә булган санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килүенә санитар-эпидемиологик экспертиза;

балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә эшләргә җибәрелә торган хезмәткәрләрнең гигиена күнекмәләре һәм профилактик медицина күзәтүен, балаларның санитар-эпидемиологик тәэмин ителеше максатыннан лаборатор инструменталь тикшерүләр уздыруны;

җәйге чорга балигъ булмаганнарны вакытлыча эш белән тәэмин итүне рәсмиләштергәндә медицина күзәтүен түләүсез генә уздырырга.

3. “Биектау муниципаль районы мәшгульлек үзәге” дәүләт бюджет учреждениесенә тәкъдим итәргә:

билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитларын һәм чыгымнарны финанслау күләме чикләрендә 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан буш вакытларында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырырга;

укудан буш вакытларында 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булу турында халыкка мәгълүмат җиткерү буенча эшне оештырырга;

беренче чиратта Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау муниципаль районы эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаган балалар белән эшләү бүлекчәсендә һәм районның балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә хисапта торган балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру буенча чаралар уздырганда, 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарга хезмәт хакы түләү эш бирүче хисабыннан федераль законнар тарафыннан билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән дә ким булмаган суммада тормышка ашырыла дигән нигезләмә белән эш йөртергә тиешләр; күрсәтелгән категория гражданнарга материаль ярдәм күрсәтү (килешү буенча) “Биектау муниципаль районы мәшгульлек үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе хисабына, бер кешегә аена эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 1,5 тапкыр зурлыгына тигез булган суммада тормышка ашырыла.

5. “Биектау үзәк хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибына тәкъдим итәргә:

мәктәп яны лагерьларын медицина кадрлары белән тулыландырырга;

балигъ булмаган балаларга укудан буш вакытларында һәм каникул вакытында вакытлыча эшкә урнашуны рәсмиләштергәндә медицина тикшерүләре оештыруны түләмичә тәэмин итәргә;

җәйге стационар һәм мәктәп яны лагерьлары хезмәткәрләренең профилактика чараларында амбулатора-поликлиника ярдәме учреждениеләре аркылы медицина тикшеренүе узуны түләүсез генә тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

6. Россия гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча дәүләт янгын надзоры дәүләт учрежденесе Идарәсенең Биектау районы дәүләт надзоры бүлегенә сәламәтләндерү учреждениеләрендә һәм массалы ял урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә тәкъдим итәргә:

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә” санаторий базаларында һәм сәламәтләндерү учреждениеләрендә ял һәм сәламәтләндерүне оештыру өчен авыр тормыш халәтендә булган һәм социаль куркыныч хәлдә булган балалар турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

8. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә, тәэмин итәргә:

2019 елның 5 нче июненә кадәр көндезге мәктәп яны лагерьларының ачылышын тәэмин итәргә;

лагерьларның вакытында ачылуы, аларны кабул итү, лагерь хезмәткәрләрен өйрәтү буенча вакытында эш алып бару;

2019 елның маенда җитәкчеләр тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, балалар сәламәтләндерү лагерьларында эшләүче барлык педагогик составка һәм барлык хезмәткәрләргә хезмәтне саклау, янгын-техник минимумы программалары һәм гигиена әзерлеге буенча өйрәтүләр уздырырга;

мәктәп укучыларының шәхси эшкә урнашуын, мәктәп яны кишәрлекләрендәге эшләрне, балалар мәйданчыклары эшен контрольдә тоту;

мәктәп балаларының эше һәм ялының оештырылган формлары белән ятим балаларга, авыр тормыш халәтендә булган балаларга, Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау муниципаль районы эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаган балалар белән эшләү бүлекчәсендә һәм районның балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә хисапта торган балигъ булмаганнарга аеруча игътибар биреп максималь колачлау;

мәгариф системасының сәламәтләндерү лагерьларында эшләргә җибәрелә торган педагогик кадрларны Республика мәктәптән тыш эшләре үзәге базасында укыту;

Республика профильле лагерьлары һәм сменаларына (балалар йортлары һәм мәктәп-интернатта тәрбияләнүчеләр өчен лагерьлар һәм сменаларны да кертеп) җибәрелә торган педагогик составка һәм ведомство кармагында булган учреждение хезмәткәрләренә төп эш урынындагы хезмәт хакын саклау.

9. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

җәйге чорга балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм эш белән тәэмин итүен оештыру буенча әзерлек эшләре алып барырга;

стационар һәм палаткалы лагерьлар оештыру буенча әзерлек эшләре алып барырга;

2019 елның июнь, август айларында спорт секцияләре эше;

авыр тормыш хәлендә һәм социаль куркыныч ситуацияләрдә булган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен санаторий базаларында һәм сәламәтләндерү учреждениеләрендә оештыруны тәэмин итәргә;

Социаль реабилитациягә мохтаҗ булган балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләр өчен ял һәм сәламәтләндерүне оештыруны тәэмин итү.

10.. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе мәдәният бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә 2019 елның җәйге чорында мәктәп яны сәламәтләндерү лагерьларында күчмә китапханәләр эшен оештырырга.

11. Шуны ачыкларга:

2019 елда балаларның һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерүе, эш белән тәэмин итүелеше Татарстан Репсубликасы бюджет чаралары, Биектау муниципаль районы бюджет чаралары, бюджеттан тыш чаралар, әти-әниләр акчалары һәм коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмаларның чыганаклары хисабына тормышка ашырыла.

12. Район башкарма комитетының икътисад бүлегенә стационар лагерьларның профильле сменаларына юлламалар алуга торглар уздырырга.

13. Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы бюджеты чараларыннан түләүләрне “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе мәдәният бүлеге” һәм “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Чыршы” балалар сәламәтләндерү лагеры” муниципаль бюджет учреждениесе аша уздырырга киңәш итәргә.

14. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

15. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Сабирҗанов Р.Р.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта

Килешенгән:
Республика «Җәй» балалар һәм
яшүсмерләрне сәламәтләндерү
һәм эш белән тәэмин итүне оештыру
үзәге Дәүләт бюджет учреждениесе
Директор _____________ Муратшин Р.Ш.

Расланган
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Биектау
башкарма комитеты карары белән
06.02.2019 № 237

# 2019 ЕЛГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛ ИТҮ, СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ ҺӘМ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ПРОГРАММАСЫ

# 1. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019 елда Биектау муниципаль районы балаларының һәм<br>яшьләренең ялын һәм эш белән тәэмин итүне<br>оештыру Программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказчы | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны төп эшләүчеләре | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның төп башкаручылары | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе; “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;<br>“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе;<br>“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы” муниципаль казна учреждениесе. |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | - Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, каникул вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итү;<br>- балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин итүен оештыру өчен шартлар тудыру;<br>- балаларның тормыш-көнкүрешен яхшырту һәм имин булмаган балаларның проблемаларын хәл итү;<br>- балалар һәм яшьләрнең ял, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү, балалар һәм яшьләр туризмы һәм спортының төрле рәвешләрен үстерү;<br>- балалар һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү инфраструктурасын саклау һәм ныгыту;<br>- балалар арасында авырулар һәм инвалидлык профилактикасы;<br>- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2019 нчы елның мартыннан 2020 елның мартына кадәр. |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен стационар һәм палаткалы лагерьларда профильле сменалар оештыру.<br>2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге лагерьларында сменалар оештыру.<br>3. Хезмәт һәм ял лагерьларында көндезге сменалар оештыру.<br>4. Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең һәм хуҗалык итүче субъектлар хезмәткәрләренең балалары (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) ялын стационар лагерьлардагы сменаларда оештыру. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2019 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 11446,00 мең сум, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан ял һәм сәламәтләндерүне оештыруга субсидияләр - 9 798,20 мең сум;<br>Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан ял һәм сәламәтләндерүне оештыруга субсидияләр – 23,00 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан предприятие һәм учреждение хезмәткәрләренең балалары ялын оештыруга субсидияләр –11,90 мең сум;<br>оешмаларның чаралары – 34,80 мең сум;<br>эти-әниләрнең чаралары – 1 578,10 мең сум. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балаларны каникул вакытында ял итү һәм сәламәтләндерүнең төрле формалары белән 50 проценттан да ким булмаган дәрәҗәдә тәэмин итү.<br>Уздырылган барлык программа чаралары йомгаклары буенча белдерелгән сәламәтләндерү нәтиҗәсенең 90 проценттан да ким булмаган дәрәҗәсенә ирешү. |

## 2. ӘЛЕГЕ ПРОГРАММА КЫСАЛАРЫНДА РАСЛАНГАН ХЕЗМӘТЛӘР КҮЛӘМЕ НОРМАТИВЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР

| Чаралар исеме | Үткәрү вакыты | Кеше саны | Оештыру өчен җаваплы (башкаручы) |
| --- | --- | --- | --- |
| Иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен стационар һәм палаткалы лагерьларда профильле сменалар оештыру. | 2019 елның май-октябре | 100 | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |
| Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге лагерьларында сменалар оештыру. | 2019 елның июнь-июле,<br><br>2019 елның декабре | 700<br><br>450 | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе |
| Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең һәм хуҗалык итүче субъектлар хезмәткәрләренең балалары (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) ялын стационар лагерьлардагы сменаларда оештыру. | 2019 елның май-декабре | 225<br><br>5 | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |
| Стационар лагерьларда профильле сменалар оештыру | 2019 елның май-декабре<br>2019 елның декабре – 2020 елның марты | 150<br><br>200 | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Хезмәт һәм ял лагерьларында көндезге сменалар оештыру | 2019 елның июне | 300 | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе |

## 3. ИҖАДИ СӘЛӘТЛЕ ҺӘМ СОЦИАЛЬ АКТИВ БАЛАЛАР ҺӘМ ВОЛОНТЕРЛАР, БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘР ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕ АКТИВЫ ӘГЪЗАЛАРЫ, БАЛАЛАРГА ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘНҮЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ПАЛАТКАЛЫ ЛАГЕРЬЛАРДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Палаткалы лагерь (оештыручы) исеме | Уздыру территориясе | Кеше саны * | Көннәр саны * | 1 юлламаның орматив бәясе, сум | Бюджеттан субсидияләр, сум** | Ата-аналарның кертеме, сум** | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет), сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| “Чыршы” БСЛ МБУ | Биектау муниципаль районы (Чыршы авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт) | 100 | 7 | 6 450,15 | 548 262,75 | 96 752,25 | 0 |

## 4. ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ КӨНДЕЗГЕ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Лагерь оештыру өчен база (мәктәп) | Уздыру территориясе | Кеше саны * | Көннәр саны * | 1 юлламаның орматив бәясе, сум | Бюджеттан субсидияләр, сум** | Ата-аналарның кертеме, сум** | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет), сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда | | | | | | | |
| Әлдермеш урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Әлдермеш авылы, Хәбибуллин ур., 18 нче йорт | 25 | 21 | 3450,30 | 73321,50 | 12 936,00 | 821,00 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Бөреле җәнлек совхозы бистәсе, Интернационал сугышчылар ур., 12 нче йорт | 70 | 21 | 3450,30 | 205300,20 | 36220,80 | 2300,00 |
| 1 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Биектау авылы, Гагарин ур., 9 нчы йорт | 80 | 21 | 3450,30 | 234628,80 | 41395,20 | 2628,00 |
| 2 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Биектау авылы, Полковая ур., 16 нчы йорт | 140 | 21 | 3450,30 | 410526,90 | 71934,42 | 4599,00 |
| 4 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Биектау авылы, Х.Бигичев ур., 5 нче йорт | 70 | 21 | 3450,30 | 205300,20 | 36220,80 | 2304,00 |
| Дөбъяз урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Дөбьяз авылы, Ленин ур., 35а йорты | 45 | 21 | 3450,30 | 131978,70 | 23284,80 | 1478,00 |
| Коркачык урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Коркачык авылы, Төзүчеләр ур., 5 нче йорт | 45 | 21 | 3450,30 | 131978,70 | 23284,80 | 1478,00 |
| Мүлмә урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Мүлмә авылы, Үзәк ур., 23 нче йорт | 20 | 21 | 3450,30 | 58657,20 | 10348,80 | 657,00 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Усад урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Усад авылы, Мәктәп ур., 1 нче йорт | 35 | 21 | 3450,30 | 102650,10 | 18110,40 | 1150,00 |
| Чернышевка урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Чернышевкаавылы, Мәктәп ур., 1 нче йорт | 30 | 21 | 3450,30 | 87985,80 | 15523,20 | 986,00 |
| Чыпчык урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Чыпчык авылы, Мәктәп ур., 1 нче йорт | 60 | 21 | 3450,30 | 175971,60 | 31046,40 | 1971,00 |
| Шәпше урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Шәпше авылы, Ленин ур., 3 нче йорт | 45 | 21 | 3450,30 | 131978,70 | 23284,80 | 1478,00 |
| Ямашурмә урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Ямашурмә авылы, Мәктәп ур., 13 нче йорт | 35 | 21 | 3450,30 | 102650,10 | 18110,40 | 1150,00 |
| БАРЛЫГЫ | - | 700 | - | - | 2 052 928,50 | 361700,82 | 23000 |
| | | | | | | | |
| Калган чорда | | | | | | | |
| Әлдермеш урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Әлдермеш авылы, Хәбибуллин ур., 18 нче йорт | 20 | 7 | 1 150,10 | 19552,40 | 3449,60 | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Бөреле җәнлек совхозы бистәсе, Интернационал сугышчылар ур., 12 нче йорт | 50 | 7 | 1 150,10 | 48881,00 | 8624,00 | - |
| 1 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Биектау авылы, Гагарин ур., 9 нчы йорт | 50 | 7 | 1 150,10 | 48881,00 | 8624,00 | - |
| 2 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Биектау авылы, Полковая ур., 16 нчы йорт | 55 | 7 | 1 150,10 | 53753,35 | 9502,15 | - |
| 3 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | Высокогорский район, с.Высокая Гора, ул. Татарстан, д.25 Биектау районы Биектау авылы, Татарстан ур., 25 нче йорт | 50 | 7 | 1 150,10 | 48881,00 | 8624,00 | - |
| 4 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Биектау авылы, Х.Бигичев ур., 5 нче йорт | 40 | 7 | 1 150,10 | 39104,80 | 6899,20 | |
| Дөбъяз урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Дөбьяз авылы, Ленин ур., 35а йорты | 30 | 7 | 1 150,10 | 29328,60 | 5174,40 | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Коркачык урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Коркачык авылы, Төзүчеләр ур., 5 нче йорт | 25 | 7 | 1 150,10 | 24440,50 | 4312,00 | - |
| Мүлмә урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Мүлмә авылы, Үзәк ур., 23 нче йорт | 20 | 7 | 1 150,10 | 19552,40 | 3449,60 | - |
| Усад урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Усад авылы, Мәктәп ур., 1 нче йорт | 25 | 7 | 1 150,10 | 24440,50 | 4312,00 | - |
| Чыпчык урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Чыпчык авылы, Мәктәп ур., 1 нче йорт | 30 | 7 | 1 150,10 | 29328,60 | 5174,40 | - |
| Шәпше урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Шәпше авылы, Ленин ур., 3 нче йорт | 25 | 7 | 1 150,10 | 24440,50 | 4312,00 | - |
| Ямашурмә урта гомуми белем бирү мәктәбе | Биектау районы Ямашурмә авылы, Мәктәп ур., 13 нче йорт | 30 | 7 | 1 150,10 | 29328,60 | 5174,40 | - |
| БАРЛЫГЫ | - | 450 | - | - | 439 913,25 | 77631,75 | |

## 5. МУНИЦИПАЛЬ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ БАЛАЛАРЫ КОММЕРЦИЯЛЕ ҺӘМ КОММЕРЦИЯЛЕ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАР ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ (ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРДӘН ТЫШ)

| Стационар БСЛ исеме | Уздыру территориясе | БСЛны балансна тотучының исеме | Кеше саны * | Көннәр саны * | 1 юлламаны норматив бщясе, сум | Бюджеттан субсидияләү, сум.** | Ата-аналар кертеме, сум** | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет), сум ** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль йөкләмә нигезендә | | | | | | | | |
| “Чыршы” БСЛ МБУ | Биектау муниципаль районы (Чыршы авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт) | - | 225 | 21 | 16 360,05 | 3 128 859,56 | 552 151,69 | - |
| “Чыршы” БСЛ МБУ | Биектау муниципаль районы (Чыршы авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт) | - | 5 | 21 | 16 360,05 | 34 843,74 | 12 270,04 | 34 765,11 |

## 6. СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬЛАРДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Стационар БСЛ исеме | Уздыру территория се | БСЛны балансtargetотучыны ң исеме | Кеше саны * | Көннәр саны * | Юлламаны ң норматив бәясе, сум | Бюджеттан субсидияләр, сум.** | Ата-аналар кертеме, сум** | Башка чаралар (предприятие ләр, җирле бюджет), сум ** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль йөкләмә нигезендә | | | | | | | | |
| “Чыршы” БСЛ МБУ | Биектау муниципал ь районы (Чыршы авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт) | Биектау муниципа ль районы Башкарма комитеты | 150 | 18 | 13 977,36 | 1 782 113,40 | 314 490,60 | - |
| “Чыршы” БСЛ МБУ | Биектау муниципал ь районы (Чыршы авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт) | Биектау муниципа ль районы Башкарма комитеты | 150 | 7 | 5 435,64 | 693 044,10 | 122 301,90 | - |
| Торглар нәтиҗәләре буена | Биектау муниципал ь районы | - | 50 | 7 | 5 435,64 | 231 014,70 | 40 767,30 | - |

## 7. КӨНДЕЗГЕ ЯЛ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Лагерь исеме | Кеше саны * | Көннәр саны * | юлламаның норматив бәясе, сум | Бюджеттан субсидияләр, сум.** | Ата-аналар кертеме, сум** | Башка чаралар (предприят иеләр, җирле бюджет), сум ** |
|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Әлдермеш урта гомуми белем бирү мәктәбе | 15 | 18 | 2957,40 | 44361,00 | - | - |
| Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе | 30 | 18 | 2957,40 | 88722,00 | - | - |
| 1 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | 40 | 18 | 2957,40 | 118296,00 | - | - |
| 2 нче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | 70 | 18 | 2957,40 | 207018,00 | - | - |
| 4 нче номерлы иектау урта гомуми белем бирү мәктәбе | 45 | 18 | 2957,40 | 133083,00 | | |
| Дөбъяз урта гомуми белем бирү мәктәбе | 20 | 18 | 2957,40 | 59148,00 | - | - |
| Коркачык урта гомуми белем бирү мәктәбе | 13 | 18 | 2957,40 | 38446,20 | - | - |
| Мүлмә урта гомуми белем бирү мәктәбе | 10 | 18 | 2957,40 | 29574,00 | - | - |
| Усад урта гомуми белем бирү мәктәбе | 17 | 18 | 2957,40 | 50275,80 | - | - |
| Чернышевка урта гомуми белем бирү мәктәбе | 10 | 18 | 2957,40 | 29574,00 | - | - |
| Шәпше урта гомуми белем бирү мәктәбе | 10 | 18 | 2957,40 | 29574,00 | - | - |
| Ямашурмә урта гомуми белем бирү мәктәбе | 20 | 18 | 2957,40 | 59148,00 | - | - |
| БАРЛЫГЫ | 300 | - | - | 887220,00 | - | - |

## 8. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫ АКЧАЛАРЫННАН БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ҺӘМ СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮЕН ОЕШТЫРУ ӨЧЕН СУБСИДИЯЛӘР

| Күрсәткеч атамасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан бүлеп бирелгән субсидияләр, мең сум |
|---|---|
| Муниципаль районның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре һәм хуҗалык итүче субъектлар (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) хезмәткәрләренең балалары арасыннан бер балага Татарстан Республикасында балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өчен финанс чыгымнары нормативы | 11,9 |

## 9. БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ҺӘМ СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮЕН ОЕШТЫРУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ ТӘКЪДИМ ИТҮГӘ НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

Көндезге мәктәп яны лагерьларында булуына норматив чыгымнар

| | Бюджет, сум | Ата-аналар кертеме, сум |
|---|---|---|
| Туклану | 117,32 | 20,70 |
| Өстәлгән сумма белән хезмәт хакы | 9,12 | 1,61 |
| Хуҗалык чыгымнары | 10,81 | 1,9 |
| Медикаментлар | 2,41 | 0,43 |

Хезмәт һәм ял лагерьларында норматив чыгымнар

| | Бюджет, сум |
|---|---|
| Туклану | 138,02 |
| Өстәлгән сумма белән хезмәт хакы | 10,73 |
| Хуҗалык чыгымнары | 12,71 |
| Медикаментлар | 2,84 |

Стационар лагерьларда норматив чыгымнар

| | Бюджет, сум | Ата-аналар кертеме, сум |
|---|---|---|
| Туклану | 255,43 | 45,08 |
| Өстәлгән сумма белән хезмәт хакы | 184,81 | 32,61 |
| Хуҗалык чыгымнары (болардан хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләргә хезмәт хакын түләүне дә кертеп) | 218,55 (25,63) | 38,57 (4,52) |
| Мәдәни хезмәт күрсәтү | 3,4 | 0,6 |
| Медикаментлар | 7,16 | 1,26 |

Стационар лагерьларның профильле сменаларында норматив чыгымнар

| | Бюджет, сум | Ата-аналар кертеме, сум |
|---|---|---|
| Туклану | 255,43 | 45,08 |
| Өстәлгән сумма белән хезмәт хакы | 137,61 | 24,28 |
| Хуҗалык чыгымнары (болардан хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләргә хезмәт | 263,60 (38,28) | 46,52 (6,76) |

| | | |
|---|---|---|
| хакын түләүне дә кертеп) | | |
| Мәдәни хезмәт күрсәтү | 3,4 | 0,6 |
| Медикаментлар | 7,25 | 1,28 |

Палаткалы типтагы лагерьларда норматив чыгымнар

| | Бюджет, сум | Ата-аналар кертеме, сум |
|---|---|---|
| Туклану | 255,43 | 45,08 |
| Өстәлгән сумма белән хезмәт хакы | 343,78 | 60,67 |
| Хуҗалык чыгымнары (болардан хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләргә хезмәт хакын түләүне дә кертеп) | 180,62<br><br>(33,09) | 31,87<br><br>(5,84) |
| Мәдәни хезмәт күрсәтү | 3,4 | 0,6 |
| Медикаментлар | 7,45 | 1,31 |

*- ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ҺӘМ СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮЕН ОЕШТЫРУ ӨЧЕН ФИНАНС ЧЫГЫМНАР НОРМАТИВЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ 2018 ЕЛ, 19 НЧЫ НОЯБРЬ, 1006 НОМЕРЛЫ КАРАРЫ НИГЕЗЕНДӘ БИЛГЕЛӘНГӘН.
** - ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫННАН БҮЛЕП БИРЕЛӘ ТОРГАН СУБСИДИЯЛӘРНЕ САНАУ КҮЛӘМЕ, АТА-АНАЛАРНЫҢ КЕРТЕМНӘРЕ, ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРНЕҢ ЧАРАЛАРЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ 2018 ЕЛ, 19 НЧЫ НОЯБРЬ, 1006 НОМЕРЛЫ КАРАРЫ НИГЕЗЕНДӘ БИЛГЕЛӘНГӘН.

2 нче кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Биектау
башкарма комитеты карары белән
06.02.2019 № 237

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру механизмын һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыруда катнашучы район башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар арасындагы мөнәсәбәтләрнең тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча вәкиллекле орган булып балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча Биектау муниципаль районы Ведомствоара комиссиясе санала. Балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча Ведомствоара комиссиянең эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

1.3. Әлеге Нигезләмә кысаларында балалар һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерүе һәм эш белән тәэмин ителүе астында каникуллар вакытында тормышка ашырыла торган, өлешчә яки тулаем билгеле бюджет чаралары хисабына финансланучы, балаларда һәм яшьләрдә шәхеснең уку һәм иҗади потенциалын үстерә, сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, авырулар профилактикасы, организмны чыныктыру, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыран, күзәтүчесез калуны һәм балигъ булмаганнарның хокук бозулары профилактикасы, җәмгыятькә файда китерә торган һәм житештерү хезмәте, физик культура, спорт, туризм һәм башка төр эшчәнлек белән шөгыльләнүне тәэмин итә торган шартлар һәм чаралар комплексы күзаллана.

2. Балалар һәм яшьләрне ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру формалары

2.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру түбәндәге формаларда тормышка ашырыла ала:

стационар лагерьдагы смена;

стационар лагерьдагы профильле смена;

палаткалы лагерьдагы профильле смена;

Кара диңгез яр буенда стационар лагерьдагы профильле смена;

көндезге (мәктәп яны) лагерьдагы смена;

санаторий-курорт учреждениесендәге смена.

2.2. Стационар лагерьдагы смена – укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе стационар базада торып, каникул вакытында балаларга белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.3. Стационар лагерьдагы профильле смена - укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе стационар базада торып, каникул вакытында иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләргә белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.4. Кара диңгез яр буенда стационар лагерьдагы профильле смена - укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе Кара диңгез яр буендагы стационар базада торып, каникул вакытында иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.5. Палаткалы лагерьдагы профильле смена - укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе кыр шартларында торып, каникул вакытында иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар (яшь техниклар, турист-туган якны өйрәнүчеләр, экологлар, спортчылар, математиклар, филологлар, журналистлар, коткаручылар, диңгезчеләр, автомобилистлар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, төрле төр балалар иҗаты кышкы һәм җәйге профильле мәктәпләре һ.б.) белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.6. Көндезге (мәктәп яны) лагерьдагы смена - каникул вакытында гомуми белем бирү һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар белән, башлыча гомуми белем бирү учреждениеләре базасында укучылар көндез анда булган һәм мәҗбүри рәвештә аларның туклануы оештырылып уздырыла торган белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.7. Санаторий- курорт учреждениесендә смена - укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе санаторий- урорт учреждениесендә торып һәм мәҗбүри рәвештә реабилитация һәм (яки) яжадан торгызу дщвалавы буенча чаралар оештырылган балалар һәм яшьләр белән сәламәтләндерү эшчәнлеге.

2.8. Вакытлыча эшкә урнаштыру – оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр базасында балигъ булмаганнар тарафыннан аларның вакытлыча эш белән тәэмин итүен һәм балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатыннан каникуллар вакытында тормышка ашырыла торган хезмәт белем бирү эшчәнлеге формасы.

2.9. Сменаларның дәвамлылыгы ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2.10. Сменалар уздырылу вакыты сменаларны оештыручылар тарафыннан билгеләнә.

2.11. Балалар лагерьларындагы отрядлар балаларның яшен һәм кызыксынуларын истә тотып туплана. Отрядларның саны билгеләнгән санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм "Шәһәр яны балаларны стационар ял итү һәм сәламәтләндерү учреждениеләренең төзелешенә, тотышына һәм эш режимын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" (СанПиН 2.4.4.1201-03) нормативлары белән билгеләнә.

## 3. Балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итүе кампанияләре катнашучылары

3.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә даими рәвештә яшәүче балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итүе кампанияләре катнашучылары булып 7 яшьтән 18 яшькә кадәр балалар һәм 30 яшькә кадәр яшьләр санала.

3.2 Балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итүен оештыру түбәндәге балалар һәм яшьләр категорияләре киселешендә тормышка ашырыла:

гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар;

югары һөнәри белем бирү учреждениеләре студентлары;

авыр тормыш ситуациясендә булган балалар;

балалар йортлары һәм ятим балалар һәм әти-әни каравыннан мәхрүм калагна балалар өчен мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләр;

муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары;

муниципаль районның коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмаларның хезмәткәрләренең балалары (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән кала);

иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләргә

Республика, Россиякүләм, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призлы урын алучылары;

хроник авырулары булган балалар, шул исәптән әти-әнисенең берсе (законлы вәкиле) озыта баруында;

районның балигъ булмаган балалар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә хисапта торучы балалар, девиант үз-үзен тотышлы балалар.

## 4. Балалар һәм яшьләр ялын, сәламтәләндерү һәм эш белән тәэмин итү сменаларын оештыручылар

4.1. Балалар һәм яшьләр ялын, сәламтәләндерү һәм эш белән тәэмин итү сменаларын оештыручылар булып (килешү буенча) Татарстан Республикасы яшьләр эшләре Министрлыгы, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгы,

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау Министрлыгы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты санала.

4.2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау минситрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар һәм яшьләр ялын, сәламтәләндерү һәм эш белән тәэмин итү сменаларын оештыручылар буларак компетенциясе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Биектау муниципаль районы башкарма комитеты гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге (мәктәп яны) лагерындагы сменаларның, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмаларның хезмәткәрләренең балалары (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән кала) өчен стационар лагерьдагы сменаларның, иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен палаткалы лагерьлардагы профильле сменаларның оештыручысы булып санала.

## 5. Балалар һәм яшьләр ялын, сәламтәләндерү һәм эш белән тәэмин итүне оештыруны финанслау тәртибе

5.1. Балалар һәм яшьләр ялын, сәламтәләндерү һәм эш белән тәэмин итүне оештыруны
финанслау түбәндәге чыганаклардан тормышка ашырыла (килешү буенча):
федераль бюджет чаралары;
Татарстан Республикасы бюджеты чаралары;
оешмаларның чаралары;
эти-әниләрнең чаралары;
законнар тарафыннан каралган башка чыганаклар.

5.2. Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабына балалар һәм яшьләр ялын, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итүне оештыруны финанслау тәртибе, Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итүне оештыруга хезмәтләр күләме нормативларын чираттагы финанс елына балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итүе смена оештыручылары һәм кампанияләре катнашучылары киселешендә, шулай ук республика бюджет чаралары хисабына балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итүен оештыруны финанслауда өлешләп катнашу тәртибе һәм күләмнәре раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый актлары белән билгеләнә.

## 6. Балаларның ялы һәм сәламәтләндерүе өчен эти-әниләр түләве күләмен билгеләү тәртибе

6.1. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә балаларның ялы һәм сәламәтләндерүе өчен әти-әниләр түләве күләме, билгеле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый акты белән бтлгеләнгән һәм Татарстан Республикасында балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру өчен финанс чыгымнар нормативыннан 15 проценттан да ким булмаган күләмдә билгеләнә.

6.2.Сәламәтләндерү учреждениеләрендә балаларның ялы һәм сәламәтләндерүе өчен әти-әниләр түләве түбәндәгеләрдән алынмый:

авыр тормыш һәм социаль-куркыныч ситуациясендә булган балалардан;

балалар йортлары һәм мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләрдән;

хроник авырулары булган балалардан, шул исәптән әти-әнисенең берсе (законлы вәкиле) озыта баруында

районның балигъ булмаган балалар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә хисапта торучы балалар, девиант үз-үзен тотышлы балалардан;

Республика, Россиякүләм, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призлы урын алучылардан.

## 7. Көндезге (мәктәп яны) лагерындагы сменада балаларны ял итү һәм сәламәтләндерүне оештыру тәртибе

7.1.Көндезге (мәктәп яны) лагерына гомуми белем бирү учреждениеләренең укучылары әти-әниләрнең (законлы вәкилләрнең) гаризалары нигезендә җибәреләләр.

7.2. Әти-әниләрнең гаризалары укучы белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесенә район башкарма комитеты мәгариф бүлеге раслаган формада бирелә.

7.3. Гомуми белем бирү учреждениеләре әти-әниләрнең гаризалары (законлы вәкилләрнең) нигезендә көндезге (мәктәп яны) лагерына җибәрелә торган гомуми белем бирү учреждениесе укучыларының исемлеген җәйге сәламәтләндерү кампаниясе өчен 50 календарь көнгә кадәр; кышкы сәламәтләндерү кампаниясе өчен 30 календарь көнгә кадәр срокларда төзиләр һәм аны район башкарма комитетының мәктәптән тыш эшләр бүлеге үзегенә җибәрәләр.

7.4. Ирекле исемлектә күрсәтеләләр:

баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

гариза биргән әти-әнинең (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

баланың туган көне, аеы, елы, җенесе;

әти-әнинең (законлы вәкилнең) эш урыны;

бала белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесе исеме;

бала белем ала торган сыйныф.

7.5. Район башкарма комитетының мәктәптән тыш эшләр бүлеге гомуми белем бирү учреждениеләре балаларының җыелма исемлеге нигезендә җәйге сәламәтләндерү кампаниясе өчен 30 календарь көнгә кадәр; кышкы сәламәтләндерү кампаниясе өчен 15 календарь көнгә кадәр срокларда муниципаль район балаларының җыелма исемлеген һәм аларның көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның ялын оештыру планын төзи.

7.6. Көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның ялын оештыру планы муниципаль районның көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның ялын оештыруга хезмәтләр күләме нормативлары чикләрендә Татарстан Репсубликасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган формада формалаша һән анда булырга тиеш:

көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның ялы оештырыла торган гомуми белем бирү учреждениеләренең исемнәре;

гомуми белем бирү учреждениеләре киселешендә көндезге (мәктәп яны) лагерьларында оештырылган урыннар саны;

гомуми белем бирү учреждениеләре киселешендә көндезге (мәктәп яны) лагерьларында оештырыла торган сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

көндезге (мәктәп яны) лагерьлары оештырыла торган гомуми белем бирү учреждениеләре һәм сменалар буенча балаларны бүлү.

7.7. Көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның ялын оештыру планнары "Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе боерыгы белән расланалар.

7.8. Көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның җәйге һәм кышкы сәламәтләндерү кампанияләре узганнан соң 30 көн эчендә район башкарма комитеты мәгариф бүлеге мәктәптән тыш эшләр үзәге Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгына көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның сәламәтләндерү кампаниясе уздыру турында хисап җибәрә.

## 8. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе

8.1. Әти-әнисенең (законлы вәкилнең) берсе муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәре булган гомуми белем бирү учреждениесе укучылары әти-әнисенең берсе (законлы вәкилнең) әти-әни (законлы вәкил) эшләүче билгеле муниципаль һәм дәүләт учреждениесе аркылы бирелгән гариза нигезендә стационар лагерьларга җибәреләләр.

8.2. Әти-әниләрнең гаризалары район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге раслаган формада, җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башлангнчыга кадәр 75 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

8.3. Муниципаль яки дәүләт учреждениесенең вәкиллекле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә торган учреждение хезмәткәрләре балаларының алдан исемлеген төзи һәм җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 70 календарь көннән дә соңга калмыйча әлеге алдан төзелгән исемлекне гаризалары район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә тапшыра.

8.4.Алдан төзелә торган исемлектә күрсәтеләләр:

учреждениенең исеме;

баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

гариза биргән әти-әнинең (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

икенче әти-әнинең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (икенче әти-әни булса);

икенче әти-әнинең эшләү урыны (әгәр дә булса);
баланың туган көне, аеы, елы, җенесе;
бала белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесе исеме;
бала белем ала торган сыйныф.
җәйге сәламәтләндерү кампаниясе вакытында баланың стационар балалар лагерында булу ае.

8.5. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге учреждениеләрнең алдан төзелгән исемлекләре нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль яки дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеген төзи.

8.6. Җыелма исемлектә күрсәтеләләр:
әти-әнинең (законлы вкилнең) эш урыны;
гариза биргән әти-әнинең (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;
баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;
баланың туган көне, аеы, елы, җенесе;
бала белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесе исеме;
бала белем ала торган сыйныф.
җәйге сәламәтләндерү кампаниясе вакытында баланың стационар балалар лагерында булу ае.

8.7. Стационар лагерьларга җибәрелүче муниципаль яки дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең җыелма исемлеккә кертелгән балалар саны арткан очракта чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган стационар лагерьларга җибәрелүче муниципаль яки дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының ялын оештыру буенча хезмәт күләме нормативлары буенча район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча муниципаль яки дәүләт учреждениеләренә агымдагы елда стационар лагерьларга җибәрелергә мөмкин булган, район территориясендә урнашкан муниципаль яки дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең уртача исемлектәге санына пропорциональ рәвештә төзелгән, әлеге муниципаль яки дәүләт учреждениесе балаларының ахыргы чик күләме турында җиткерә.

8.8. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җиткергән агымдагы елда стационар лагерьларга җибәрелергә мөмкин булган муниципаль яки дәүләт учреждениеләре балалары санының ахыргы чик күләме кысаларында муниципаль (дәүләт) учреждениесенең вәкиллекле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль (дәүләт) учреждениесе хезмәткәрләре балаларының исемлеген кабат мәртәбә төзи һәм район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә кадәр 55 көннән дә соңга калмыйча кабат мәртәбә җибәрә.

8.9. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге учреждениеләр тарафыннан тәкъдим ителгән (кабат мәртәбә тәкъдим ителгән) исемлекләр буенча стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеген төзи. Җыелма исемлек әлеге Нигезләмәнең 8.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алырга, шулай

ук муниципаль йөкләмә җиткерелә торган стационар лагерь исеме (булган очракта) яки ачык конкурс нәтиҗәләре буенча стационар лагерьларда балаларның ялын оештыруга юлламалар алу мөмкинлеге турында сылтама булырга тиеш.

8.10. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча, стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеге мәгълүматларын күз алдында тотып, стационар лагерьларда аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча план төзи.

8.11. Муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча планына керергә тиеш:

муниципаль йөкләмә нигезендә муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балалары җибәрелә торган муниципаль стационар лагерьларның исеме, урыннар һәм сменалар саны;

ачык конкурс нигезендә сатып алына торган, “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 ел, 5 нче апрель 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (28.12.2013 редакциясендә) тормышка ашырыла торган стационар лагерьларда урыннар саны һәм сменалар дәвамлылыгы;

8.12.Муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча планы “Биектау муниципаль районы башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль учреждениесе тарафыннан раслана.

8.13. Стационар лагерьларда муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү кампанияләре тәмамланганнан соң 30 көн эчендә район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча Министрлыгына һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгына стационар лагерьларда муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының сәламәтләндерү кампаниясе уздыру турында хисап җибәрә.

## 9. Муниципаль районның коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмалары (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән кала) хезмәткәрләре балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе

9.1. Әти-әнисенең (законлы вәкилнең) берсе Биектау муниципаль район территориясендә урнашкан коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмалары (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән кала) хезмәткәре (алга таба - оешма) булган гомуми белем бирү учреждениесе укучылары әти-әнисенең берсе (законлы вәкилнең) әти-әни (законлы вәкил) эшләүче оешманың вәкиллекле органына (вазыйфаи затына) бирелгән гариза нигезендә стационар лагерьларга җибәреләләр.

9.2. Әти-әниләрнең гаризалары район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге раслаган формада, җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башлангнчыга кадәр 75 көннән дә соңга калмыйча бирелә. Гаризага икенче әти-әнинең эш урыныннан баланыд агымдагы елда җирле бюджет хисабына башка стационар лагерьга җибәрелмәве турында белешмә беркетелә.

9.3. Оешманың вәкиллекле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә торган оешма хезмәткәрләре балаларының алдан исемлеген төзи һәм җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 70 календарь көннән дә соңга калмыйча әлеге алдан төзелгән исемлекне гаризалары район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә тапшыра.

9.4.Алдан төзелә торган исемлектә күрсәтеләләр:

оешманың исеме;

баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

гариза биргән әти-әнинең (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

икенче әти-әнинең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (икенче әти-әни булса);

икенче әти-әнинең эшләү урыны (әгәр дә булса);

баланың туган көне, аеы, елы, җенесе;

бала белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесе исеме;

бала белем ала торган сыйныф.

җәйге сәламәтләндерү кампаниясе вакытында баланың стационар балалар лагерында булу ае.

9.5. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге оешмаларның алдан төзелгән исемлекләре нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә торган оешмаларның хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеген төзи.

9.6. Алдан төзелгән җыелма исемлектә күрсәтеләләр:

әти-әнинең (законлы вәкилнең) эш урыны;

гариза биргән әти-әнинең (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

баланың туган көне, аеы, елы, җенесе;

бала белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесе исеме;

бала белем ала торган сыйныф.

җәйге сәламәтләндерү кампаниясе вакытында баланың стационар балалар лагерында булу ае.

9.7. Стационар лагерьларга җибәрелүче оешмалар хезмәткәрләренең җыелма исемлеккә кертелгән балалар саны арткан очракта чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган стационар лагерьларга җибәрелүче оешмаларның хезмәткәрләре балаларының ялын оештыру буенча хезмәт күләме нормативлары буенча район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча оешмаларга агымдагы елда стационар лагерьларга җибәрелергә мөмкин булган, район территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең уртача исемлектәге санына пропорциональ рәвештә төзелгән, әлеге оешмалар балаларының ахыргы чик күләме турында җиткерә.

9.8. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җиткергән агымдагы елда стационар лагерьларга җибәрелергә мөмкин булган оешмалар балалары санының ахыргы чик күләме кысаларында оешманың вәкиллекле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә торган оешма хезмәткәрләре

балаларының исемлеген кабат мәртәбә төзи һәм район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә кадәр 55 көннән дә соңга калмыйча кабат мәртәбә җибәрә.

9.9. Оешма хезмәткәрләре балалары исемлеген җибәргән вакытта аның вәкиллекле органы (вазыйфаи заты) район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә стационар лагерьларга юлламалар алган вакытта өлешчә финанслауда һәрбер юлламаның норматив бәясеннән 42,5 проценты күләмдә катнашуы турында хәбәр ителгән, оешманың җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хатын юллый.

9.10. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге оешмалар тарафыннан тәкъдим ителгән (кабат мәртәбә тәкъдим ителгән) исемлекләр буенча стационар лагерьларга җибәрелә торган оешмалар хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеген төзи. Җыелма исемлек әлеге Нигезләмәнең 9.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алырга, шулай ук муниципаль йөкләмә җиткерелә торган стационар лагерь исеме (булган очракта) яки ачык конкурс нәтиҗәләре буенча стационар лагерьларда балаларның ялын оештыруга юлламалар алу мөмкинлеге турында сылтама булырга тиеш.

9.11. Район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча, стационар лагерьларга җибәрелә торган оешма хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеге мәгълүматларын күз алдында тотып, стационар лагерьларда аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча план төзи.

9.12. Оешмалар хезмәткәрләре балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча планына керергә тиеш:

муниципаль йөкләмә нигезендә оешмалар хезмәткәрләре балалары җибәрелә торган муниципаль стационар лагерьларның исеме, урыннар һәм сменалар саны;

ачык конкурс нигезендә сатып алына торган, “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 ел, 5 нче апрель 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (28.12.2013 редакциясендә) тормышка ашырыла торган стационар лагерьларда урыннар саны һәм сменалар дәвамлылыгы;

9.13. Оешма хезмәткәрләре балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча планы район башкарма комитеты карары белән раслана.

9.14. Стационар лагерьларда оешмалар хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү кампанияләре тәмамланганнан соң 30 көн эчендә район башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына стационар лагерьларда муниципаль һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре балаларының сәламәтләндерү кампаниясе уздыру турында хисап җибәрә.

## 10.Авыр тормыш ситуациясендә калган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе

10.1. Авыр тормыш ситуациясендә калган балалар стационар лагерьларга район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә бирелгән әти-әнисенең берсенең (законлы вәкилнең, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешма җитәкчеләре) гаризасы нигезендә җибәреләләр.

10.2. Авыр тормыш ситуациясендә калган балаларга керәләр:

бер кешегә уртача кереме Татарстан Республикасындагы билгеләнгән эшләүче халыкның яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрдә тәрбияләнүче, шул исәптән күп балалы гаиләләрдән, тулы булмаган гаиләләрдән, әти-әниләре пенсионерлар һәм инвалидлар булган гаиләләрдән балалар;

социаль яктан авыр хәлдә калган балалар (аларның яшәүләре һәм сәламәтлекләренә куркыныч тудырган яки балаларны тәрбияләү һәм карауга тиешле таләпләргә туры килми торган хәл);

Социаль реабилитациягә мохтаҗ булган балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешмада тәрбияләнүчеләр.

10.3. Әти-әниләрнең (законлы вәкилнең, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешма җитәкчеләре) гаризалары Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль ярдәм Министрлыгы тарафыннан раслаган формада, җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчыга кадәр 75 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

10.4. Хисап тәртибе, юлламалар бирү, һәм авыр тормыш ситуациясендә калган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча башка төр мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## 11. Стационар (палаткалы) лагерьларның, шул исәптән Кара диңгез яр буенда да профильле сменаларында балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе

11.1.Стационар (палаткалы) лагерьларның профильле сменаларында, шул исәптән Кара диңгез яр буенда да катнашу өчен республика, Россиякүләм, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призлы урын алучылар, иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр җибәрелә.

11.2. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар стационар (палаткалы) лагерьларга әти-әниләренең берсенең (законлы вәкилнең) район башкарма комитетының тиешле бүлеге аша профильле сменаларны оштыручыларга - Татарстан Республикасының вәкиллекле органына (Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына) һәм муниципаль җирле үзидарә органына бирелгән гариза нигезендә җибәреләләр.

11.3. Әти-әниләрнең гаризалары профильле сменаларны оештыручылар тарафыннан расланган формада кышкы һәм җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 60 календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

11.4. Профильле сменаларны оештыручылар стационар (палаткалы) лагерьларга җибәрелә торган балаларның - профильле сменалар катнашучыларының җыелма исемлеген төзиләр.

11.5. Профильле сменаның һәрбер катнашучысы буенча җыелма исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

әти-әнинең (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;

әти-әнинең эшләү урыны (законлы вәкилләрнең);

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

бала белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесе исеме;

бала белем ала торган сыйныф.

сменада катнашучы бала (әгъза булып торган) йөри торган (әгәр дә булса) балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе, иҗтимагый оешма, иҗтимагый яшьләр оешмасы исеме;

баланың уңышлары исемлеге яки иҗтимагый оешмалардан яки берләшмәләрдән рекомендацияләр;

җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында баланың стационар (палаткалы) лагерьда булу ае;

дәүләт (муниципаль) йөкләмәсе нигезендә профильле смена оештырыла торган стационар (палаткалы) лагерьның исеме яки ачык конкурс нәтиҗәләре буенча стационар лагерьларда балаларның ялын оештыруга юлламалар алу мөмкинлеге турында сылтама.

11.6. Профильле сменаларны оештыручы җәйге һәм кышкы сәламәтләндерү кампаниясенә кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча, стационар (палаткалы) лагерьларның профильле сменаларына җибәрелә торган балаларының җыелма исемлеге мәгълүматларын күз алдында тотып, стационар (палаткалы) лагерьларның профильле сменаларда аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча план төзи.

11.7. Профильле сменаларда катнашучыларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча планына керергә тиеш:

муниципаль йөкләмә нигезендә профильле сменалар катнашучылары җибәрелә торган стационар (палаткалы) лагерьларның исеме, урыннар һәм сменалар саны;

ачык конкурс нигезендә сатып алына торган, "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 ел, 5 нче апрель 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (28.12.2013 редакциясендә) тормышка ашырыла торган стационар лагерьларда урыннар саны һәм сменалар дәвамлылыгы;

11.8. Профильле сменаларның катнашучылары - балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча план профильле сменаларны оештыручыларның карар бирү документлары белән раслана.

11.9. Стационар (палаткалы) лагерьларның профильле сменалары тәмамланганнан соң 30 көн эчендә, профильле сменаларны оештыручылар Татарстан Республикасы вәкаләтле органына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына стационар (палаткалы) лагерьларда профильле сменалар узуы турында хисап җибәрә.

## 12. Хроник авырулары булган, шул исәптән бер әти-әни (законлы вәкил) озатып йөргүендә, балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе

12.1. Хроник авырулары булган, шул исәптән бер әти-әни (законлы вәкил) озатып йөрүендә, балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау Министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

12.2. Санаторий –курорт учреждениеләрендә сменалар оештырган вакытта 4 яшькә мәктәп яшенә кадәр, хроник авырулары булган, шул исәптән бер әти-әни (законлы вәкил) озатып йөрүендә, балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру рөхсәт ителә.

3 нче кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Биектау
башкарма комитеты карары белән
06.02.2019 № 237

Биектау муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча Биектау муниципаль районы ведомствоара комиссиясе (алга таба - Комиссия) балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, эш белән тәэмин итүен оештыру максатларында оештырылган һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының координацияләүче органы булып тора.

2. Комиссияне бер урынбасары булган рәис җитәкли. Комиссия составына район башкарма комитетының кызыксынган бүлекләре һәм Биектау муниципаль районында Башкарма хакимият органнарының территориаль органнары керәләр.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне әзерләү һәм оештыру буенча башкарма комитет бүлекләре, районның башка җирле үзидарә органнары, төрле фондлар, акционер җәмгыятьләре, барлык төр милек формасында булган предприятиеләр, иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеген координацияләү;

ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча башкарма комитет бүлекләре, оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлегенә анализ, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматны Комиссия утырышларында тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, эш белән тәэмин итүен финанслау һәм оештыру мәсьәләләрен карау.

балалар һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерүе, эш белән тәэмин итү программаларын тормышка ашыруны контрольдә тоту.

5. Комиссия хокуклы:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балалары һәм яшьләренең ялы, сәламәтләндерүе, эш белән тәэмин итү буенча тәкъдимнәр эшләргә һәм аларны раслау өчен вәкаләтле органнарга каралырга кертергә;

балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, эш белән тәэмин итүен оештыру мәсьәләләре буенча башкарма комитетка тәкъдимнәр эшләргә һәм кертергә;

балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, эш белән тәэмин итүен оештыруда катнашучы башкарма комитет бүлекләреннән, районның башка җирле

үзидарә органнарыннан, предприятие, учреждение, оешмалардан аларның компетенциясенә караган документлар, мәгълүматлар, материаллар соратып алырга;

балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, эш белән тәэмин итүен оештыру мәсьәләләре буенча район башкарма комитеты карарлары үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

район балалары һәм яшьләренең балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, эш белән тәэмин итүен оештыру буенча гамәлдә булган программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча башкарма комитетка тәкъдимнәр кертү.

6. Комиссия тарафыннан аның компетенциясендә кабул ителгән карарлар район башкарма комитетының барлык бүлекләре тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш һәм районның башка җирле үзидарә органнарына, учреждение, предприятие һәм оешмалар өчен киңәш итү характерында була.

7. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, утырышлар беркетмәләре белән рәсмиләштерелә һәм үтәлү өчен кабул ителгән карарлар кагыла торган субъектларга җибәрелә.

Утырышлар беркетмәләре Комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

4 нче кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Биектау
башкарма комитеты карары белән
06.02.2019 № 237

Биектау муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча (килешү буенча) Ведомствоара комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Сабирҗанов Ринат Рәшит улы | -“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе |
| Миңнебаев Нәфис Наил улы | -“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” муниципаль казна учреждениесе “Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесе начальнигы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Ларин Алексей Евгений улы | -“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” муниципаль казна учреждениесе “Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль казна учреждениесе баш белгече, комиссия сәркатибе; |
| Афанасьев Алексей Павел улы | --“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары; |
| Камалиев Илнар Фәнис улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлеге начальнигы; |
| Салкова Эльвира Валентин кызы | - Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор территориаль идарәсенең Арча, Биектау районнарындагы бүлеге начальнигы; |
| Зыятдинов Рамил Равил улы | - “Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы; |
| Разгулов Алексей Михаил улы | -күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе һәм профилактика эшләре Биектау муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге начальнигы; |

| | |
|---|---|
| Вәлиуллина Рамилә Шамил кызы | -“Татарстан Репсубликасы Биектау муниципаль районы Финанс- бюджет палатасы” муниципаль казна учреждениесе рәисе; |
| Савинова Наталья Анатолий кызы | -Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Татарстан Репсубликасы Биектау муниципаль районы территориаль бүлеге җитәкчесе; |
| Газизуллина Лениза Шамил кызы | - “Татарстан Республикасы Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” Дәүләт казна учреждениесе директоры; |
| Минаева Гүзәл Равил кызы | -Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау Министрлыгының Биектау районындагы социаль яклау бүлеге начлаьнигы; |
| Әхмәтҗанов Нияз Камил улы | -“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе начальнигы; |
| Борһанова Лилия Зөфәр кызы | -“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе мәдәният бүлеге” муниципаль казна учреждениесе начальнигы; |
| Габидуллина Альбина Юныс кызы | -“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе баш белгече; |
| Зәйнетдинова Алия Фиркать кызы | - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” муниципаль казна учреждениесенең опека һәм попечительлек буенча баш белгече; |